ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Вөждан иреге турында һәм дини оешмалар турында” 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2), түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

“4. “Экстремистлык эшчәнлегенә каршы көрәш турында” 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законда йә “Террорчылыкка каршы көрәш турында” 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законда каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшчәнлеген туктату яисә тыю турында законлы көченә кергән карар кабул ителгән иҗтимагый яисә дини берләшмәнең йә башка оешманың элек җитәкчесе булган яисә җитәкче органы составына кергән зат тиешле суд карары законлы көченә кергән көннән алып ун ел дәвамында дини оешма төзи алмый.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 11 апреле
№ 22-ТРЗ